**Халык жыены карары**

№ 1 20.11.2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Югары Стәрле авыл җирлеге составына керүче Түбән

Стәрле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның 20 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы тезелде:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Түбән Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Түбән Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Җиңү кене»,» Сабантуй", "Халыкара елкәннәр көне»,» Инвалидлар кене", " Яңа ел», бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Түбән Стәрле авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү, спорт инвентарьлары, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу);
- Түбән Стәрле авылы зираты территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (киртәләр алу, койма ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, коймалар урнаштыру);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 51 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 35.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 35, «КАРШЫ» » позициясе ечен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дерес) дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү ечен юнэлдерергэ:

- Түбән Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Түбән Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Җиңү кене»,» Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр кене»,» Инвалидлар көне", " Яңа ел», бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Түбән Стәрле авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү, спорт инвентарьлары, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу);
- Түбән Стәрле авылы зираты территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (киртәләр алу, койма ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, коймалар урнаштыру);

3.Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г, Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан урамы , 42Г йорт , Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан урамы 19 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.